ГЛАВА КАНАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05.11.2025 д. Канаш №3

**Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Түбән Күл авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Уставының 24 ст. туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 18 ноябрендә 11.00 сәгатькә Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Түбән Күл авылы гражданнары арасында үзара салымны кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә;

1.1. 2025 елның 18 ноябрендә 12.00 сәгатькә Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Түбән Күл авылы гражданнары арасында үзара салымны кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә;

1.2. 2025 елның 18 ноябрендә 13.00 сәгатькә Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Түбән Күл авылы гражданнары арасында үзара салымны кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

2. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

1 этап: Түбән Күл авылы Үзәк урамында яшәүчеләр (9нчы йорттан 10нчы йортка кадәр); Түбән Күл авылы Мәктәп урамында яшәүчеләр (1 нче йорттан 23 нче йортка кадәр);

2 этап: Түбән Күл авылы, Яшьләр урамында яшәүчеләр (1нче йорттан 33нче йортка кадәр);

3 этап: Түбән Күл авылы, Боевая урамында яшәүчеләр (1нче йорттан 40нчы йортка кадәр)

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегенең Түбән Күл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?

«Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (товарны билгеләнгән пунктка илтеп җиткерүче исәбеннән Түбән Күл авылы юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу)»

«ӘЙЕ» «ЮК»

4. Халык җыеннарын үткәрергә

1 этап: Түбән Күл авылы Мәктәп урамы буенча 10-нчы номерлы йорт янында;

2 этап: Түбән Күл авылы Яшьләр урамы буенча 12-нче номерлы йорт янында;

3 этап: Түбән Күл авылы Боевая урамы буенча 22-нче номерлы йорт янында.

5. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Вальков